БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь 2022 ел № 158

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлегенә өстәмәләр кертү турында**

Балтач муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатыннан «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елнын 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлеген формалаштыру тәртибе, алып бару һәм бастырып чыгару турында»гы 2016 елның 11 ноябрендәге 61 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 20 декабрендәге 107 номерлы карары белән расланган Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлеген (узгэрешлэре белэн от 01.11.2018, 25.07.2019, 05.11.2019, 17.12.2019, 29.05.2020, 12.11.2020, 20.12.2021) 1 нче номерлы кушымтада исемлектән төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 20 декабрендәге 107 номерлы карары белән расланган Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач

муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлеген (узгәрешләрә белән от 01.11.2018, 25.07.2019, 05.11.2019, 17.12.2019, 29.05.2020, 12.11.2020, 20.12.2021) 2 нче номерлы кушымтада каралганча тулыландырырга.

3. Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның 1 нче һәм 2 нче кушымтаны район «Хезмәт» газетасында бастырырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», «Хезмәт» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р.Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2022 елның 15 декабрендәге
158 номерлы карарына
1 кушымта

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлектән төшереп калдырырга**

| № | Мөлкәтнең исеме | Мөлкәт урнашу урыны | Мәйдан (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар бакча бинасы | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Чепья авылы, Эшче урамы, 16 нчы йорт | 374,30 |

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2022 елның 15 декабрендәге
158 номерлы карарына
2 кушымта

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлегенә өстәмәләр**

| № | Мөлкәтнең исеме | Мөлкәт урнашу урыны | Мәйдан (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар бакча бинасы | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Шеңшеңәр авылы, Комсомольская урамы, 92 нче йорт | 627,60 |
| 2. | Балалар бакча бинасы | Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Куныр авылы, Киров урамы, 116 А нчы йорт | 679,70 |